ГЛАВА УРАХЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422661, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район, с.Урахча,
ул.Советская, дом 36а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
УРАКЧА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422661,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы,
Совет урамы, 36а йорт

Тел.: (84361) 29-435 факс: (84361) 29-435, эл.адрес: Urah.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.11 .2022** **Уракчы авылы** **№ 3**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең Урахча авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Урахча авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советының 17.10.2009 ел, №16 карарының 4.4 пункты белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 18 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта Уракчы авылында гражданнар Җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Уракчы, Николаевка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының үткәрүне билгеләргә.
2. 2022 елның 18 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Уракчы авылында гражданнар Җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Уракчы, Николаевка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының үткәрүне билгеләргә.
3. Халык җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге составына керүче Уракчы, Мельничный Починок, Наратлы, Николаевка авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре), 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы»:

-торак пунктлар чикләрендә урамнарны яктырту челтәрләрен тоту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын тәртиптә тоту (суэтем башняларына тирәнлек насослары сатып алу өчен);

- торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;

-авыл җирлеге чикләрендә кышкы юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- авыл җирлеге территориясен җәй көне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аларга комплектлаучылар өчен асылмалы җиһазлар, запас частьләр сатып алу , килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракча авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Уракча авылы, Совет урамы, 36а йорты, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Мельничный Починок авылы, Киров урамы, 20Б йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Уракчы авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Гараев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРАХЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ